*/Мәктәп тормышы/*

## *Яңа автобуслы булдык!*




2011нче елның җәендә безнең Түбән Майна урта мәктәбе Иске Әдәм авыл җирлегенең база мәктәбе статусы алды. Шушы елның август аенда төрле авыллардан балаларны йөртү өчен мәктәбебезгә **Fiat Ducato** маркалы яңа автобус бирелде. Ул заманнан алып инде 13 елдан артык гомер узып китсә дә, бу автобус әле бүгенге көндә дә укучыларыбызга лаеклы хезмәт күрсәтә. Быелның декабрь ахырына аның гомуми йөреше 326 000 км тәшкил итә. Шул дәвер эчендә бу автобус белән расланган маршрут буенча һәм якын-тирәләргә генә түгел, Казан, Болгар кебек шәһәрләргә дә күп тапкырлар сәяхәтләргә бару мөмкинлеге булды.

Автобусның яхшы хәлдә саклануында һәм юлларда хәвеф-хәтәрләрсез йөрүендә аның шофёры **Йосыпов Рифкать абыйның** өлеше зур. Үз хезмәтен зур җаваплылык белән, җиренә җиткереп башкаруы өчен балалар, аларның әти-әниләре һәм шәхсән үземнең исемнән Рифкать абыйга олы рәхмәтебезне белдерәбез. Киләчәктә дә шулай уңышлы хезмәт итүен теләп калабыз.

Беренче автобусыбыз яхшы хәлдә булуга карамастан, аның ресурсы, яки хезмәт итү вакыты 10 ел тәшкил итә. Шул сәбәпле безнең мәктәпкә әле 2021нче елда ук яңа автобус бирелергә тиеш иде. Ләкин, төрле сәбәпләр аркасында бу эш гел кичектерелде. Инде менә ел ахырында безгә дә район Башкарма комитетыннан яңа автобус алып кайтырга юллама бирелде. 23нче декабрь көнне без аны Казаннан барып алдык. **Gazelle NN** маркалы бу автобус 15 урынлы. Элеккесенә карганда урыннары азрак булса да, урындыклары зур кешеләр дә утыра алырлык, иркенрәк итеп ясалган. Бу автобуста балаларны март аеннан алып йөртергә исәплибез. Хәерле, гомерле маллар булсын, бәла-казаларсыз йөрүләр насыйп булсын дигән теләктә калыйк!

*Рафик Насыйров, мәктәп директоры*

*/Безнең спорт/*

Декабрь ае – ел ахыры. Шахматчыларнын ел ахыры булуга карамастан турнирлар графигы төгәлләнмәгән. Мәктәбебез шахматчысы Фаил Гафиятуллин да турнирларда катнашуын дәвам итеп, зур уңышларга ирешә:

- 8 декабрь – блиц төре буенча Татарстан чемпионатында 18 яшькәчә үенчылар арасында 1 урын;
- 15 декабрь – классик шахмат төре буенча Казан шәһәреннән кала башка шәһәрләр һәм район шахматчылары арасында 3 урын, Аксубай җыелма командасы составында – 2 урын. "Афәрин, Фаил!!!" - диясе генә кала.

*/Күңелле тәнәфес/*

- Әрҗә төбеннән, бура почмакларыннан себереп, бер-ике уч он белән нәрсә пешереп була?
- Агачның мунчада тәнгә ябыша торган өлеше.
- Яңа ел агачы.
- Бөтен гаилә белән тартып чыгара торган яшелчә.
- Хат юлда югалмасын өчен конвертның тышына нәрсә язалар ?
- Эш сәгатенең күпчелек өлешен куктә үткәрүче һөнәр иясе.
- Кешенең күзе начар күргәндә кия торган әйбер.
- Тиз бозыла торган әйберләр саклана торган урын.
- Нинди фигураның башы да , ахыры да юк?
- Ни өчен песинең тәпиләре йомшак?
- Кемнең дә булса өенә кергәнче нәрсә эшләргә кирәк?
- Чын дус кайчан беленә?



*/Котлыйбыз!/*



Декабрь аенда дөньяга килгән дустыбыз **Гафиятуллина Руфинәне** (IIIсыйныф) туган көне белән котлап, ныклы сәламәтлек, укуында зур уңышларга ирешүләрен телибез.

Техник хезмәткәр **Хәтмәтдинова Рәхилә апаны** да юбилее белән котлап, лаеклы ялында тормыш иминлеге, сәламәтлек телэп калабыз.

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин

# Мәктәп хәбәрчесе

**№10 (№61) декабрь 2024 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе газете*

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru




## *Яңа ел котлы булсын!*

Кадерле укучылар, укытучылар, әти-әниләр!

Барыгызны да Яңа елга аяк басуыбыз белән котлыйсыбыз килә.

Укучылар, сезгә яңа елның саф һавасы йөрәкләрегезгә көч, тырышлык, сәламәтлек өстәсен. Белемнең яңаларына омтылырга чакырабыз. Яныгызда һәрвакыт ышанычлы дуслар булсын. Ныклы адымнар белән максатларыгызга ирешегез!

Укытучыларга сәламәтлек, гаилә иминлеге телибез. Иҗадилык белән яңа белемнәрне яраткан укучыларга җиткерергә насыйп булсын. Яңа елда яңа эзләнүләр уңыш китерсен.

Әти-әниләргә дә барча изге теләкләрне телибез. Балаларыгызны тынычлыкта, иминлектә тәрбияләргә язсын. Сабыйларыбыз яратуда, гаилә җылысындауссеннәр. Яңа ел башы бит яңа өметләр өсти торган чор. Балаларыбыз өчен яхшы яктан гына үрнәк булырлык гамәлләр кылыйк.

Тирә-ягыбыз тыныч булып, сәламәт булып, һәр яхшы мөмкинлектән файдаланып, тырышып укыйк һәм эшлик.

***Бәйрәм белән котлап, "Мәктәп хәбәрчесе"редколлегиясе***

*/Мөгаллим киңәше/*

## *Балаларыбызны телефон колы итмик!*

Кемдә мәгълүмат, шул дөнья белән идарә итә, диләр. Гаджетлар хөкем сөргән дөньяда мәгълүмат диңгезендә йөзәбез. Бүгенге көндә кәрәзле телефоннар төрле яшьтәге кешеләрнең көндәлек тормышының аерылгысыз өлешенә әверелде. Балалар һәм яшүсмерләр яңа гаджетларны үзләштерә, аларда күп төрле мөмкинлекләр таба. Әмма мобиль җайланмаларны куллануның уңай яклары белән бергә бик күп проблемалар да барлыкка килә.



Шуның иң мөһиме – кәрәзле телефоннарның балаларыбыз сәламәтлегенә йогынтысы. Күзгә күренеп тора торган проблеманың иң беренчесе – ул физик яктан зәгыйфьләнү. Телефонда озак утырган баланың күз күреме начарлана, гәүдә торышы бозыла, умыртка сөяге дөрес формалашмый. Физик активлык турында оныту симерү һәм аның белән бәйле авырулар куркынычын арттыра. Шулай ук психологик аспектка да игътибар итәргә кирәк. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, телефонны чамадан тыш куллану яшүсмерләрдә борчу һәм депрессиягә китерергә мөмкин. Күп вакытны телефонда уздыру баларның йокысын, игътибарын, хәтерен бозуны китереп чыгара, бу баш миендә үзгәрешләр, аерым алганда, аның өлгерү темпларының кимүе белән бәйләнгән.

Тагын бер мөһим мәсьәлә –телефоннарның уку эшчәнлегенә йогынтысы. Күп кенә ата-аналар фикеренчә, телефон булу укучыларга үз вакытын яхшырак планлаштырырга ярдәм итә, әмма гамәлдә бар да башкача була. Социаль челтәрләрдә озак вакыт үткәрү һәм күп вакытын виртуаль уеннарда үткәргән укучылар дәрес вакытында бик пассив булалар. Бу хәл аларның өлгерешенә тискәре йогынты ясый. Чөнки алар гадәттә дәрестә йоклап утыра!

Ә сез хәтерлисезме, без ничек укый идек? Укытучылар биргән биремнәргә җавапларны интернеттан түгел, үз башыбыздан эзләдек без. Иншаларны да үзебез фикер йөртеп яза идек. Ә хәзерге буын җавапны башыннан түгел, Гуглдан эзли. Әзер материал алып фикер йөртү сәләте үсми, баш мие эшләми, үсеш алмый.

Мобиль телефоннарны куллануның социаль аспектлары турында да искә алмау дөрес булмас. Социаль челтәрләр һәм мессенджерлар балалар һәм яшүсмерләр тормышында зур роль уйный. Алар аралашу, фикер алышу урынына әверелеп бара. Хәзер балалар бергә җыелгач, хәрәкәтле уеннар түгел, ә телефон экранына төбәлеп, виртуаль уен уйныйлар. Бу бик аяныч күренеш. Кыш көннәрендә тау шуучы, чаңгыда йөрүче балалар да бик сирәк күренә. Ә бит хәрәкәт активлыгының файдалы икәне беребезгә дә сер түгел. Мондый активлык баларның физик яктан үсешенә генә генә түгел, ә стресс белән көрәшергә дә ярдәм итә. Даими күнегүләр эндорфиннар – шатлык гормоннары бүлеп чыгару аркасында кәефне яхшырта. ***(Дәвамы икенче биттә)***

## Икенче чирек һәм беренче яртыеллык нәтиҗәләре /Рәсми хәбәрләр/

Бу чирек укучылар һәм укытучылар өчен киеренке, тыгыз шартларда узды.Моңа уку яртыеллыгы тәгәлләнү һәмфән олимпиадаларының район турысәбәп булды. Боларга Яңа ел бәйрәменә әзерлек чаралары да өстәлде.

Олимпиадаларга чакырулы укучыларыбыз түбәндәге нәтиҗәләргә ирештеләр:

- V нче сыйныф укучысы **Нурматова Асия** – татар теленнән призер;
- VII сыйныф укучысы **Закирова Ләйсән** – татар теленнән җиңүче;
- VIII сыйныф укучысы **Гафиятуллин Фаил** – химиядән призер;
- VIII сыйныф укучысы **Вәлиева Мәрьям** – рус теленнән призер;
- XI сыйныф укучысы **Гафиятуллин Самат**– татар теленнән җиңүче, татар әдәбиятыннан призер;
- XI сыйныф укучысы **Нурматова Зәйнәп** – татар теленнән призер, татар әдәбиятыннан җиңүче.

Укудан тыш районкүләм конкурсларда катнашу түбәндәге нәтиҗәләрне бирде:

- II сыйныф укучысы **Хәйруллин Мансур** – ике конкурста җиңүче;
- IV сыйныфукучысы **Закиров Инсаф** – бер конкурста II урын;
- IV сыйныфукучысы **Нурматова Асия** – бер конкурста җиңүче;
- III сыйныфукучысы **Сафиуллина Гөлсем** – бер конкурста призер;

Чирек һәм яртыеллык билгеләре буенча белем сыйфаты 65% ны тәшкил итте. Отличниклар:II сыйныфтан **Хәйруллин Мансур**, III сыйныфтан **Гафиятуллина Руфинә**, IV сыйныфтан **Закиров Инсаф** белән **Камалов Илнур**, VII сыйныфтан **Закирова Ләйсән**, VIII сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил**

***Илдар Сафиуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары***

## Истәлекле көннәрне билгеләп үтү /Мәктәп тормышы/




Ил тарихында чагыштырмача яңа истәлекле бу даталардан булган“**Билгесез солдат көне**” 3 декабрьдә билгеләп үтелә. Бу көн сугыш кырларында ятып калган һәм исемнәре билгесез булган Советлар Союзы һәм Рәсәй сугышчылары турындагы хәтерне, аларның хәрби батырлыгын мәңгеләштерүгә юнәлтелгән. 3 декабрь көне очраклы гына сайланмаган. Нәкъ менә шул көнне, 1966 елны, Мәскәү янында немец-фашист гаскәрләренең тар-мар ителүенә 25 ел тулу уңаеннан Ленинград шоссесының 41нче чакрымында совет сугышчыларының Туганнар каберлегеннән билгесез солдат җәсәде Мәскәү Кремле дивары янында тантаналы рәвештә җирләнде.



Шушы ук көнне **Халыкара инвалидлар көне** дә билгеләп үтелде. Бу датаның төп бурычы – сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр (ОВЗ)булган җәмгыятьтә инвалидлар тигез мөмкинлекләргә һәм сайлау ирегенә хокуклы икәнлекләрен белдерү. Әлеге чара кысаларында башлангыч сыйныф укучылары өчен «Чикләрсез җәмгыять» кинолекториен оештырдык. Кинолекторийда инвалидлык темасына багышланган мультфильмнар күрсәтелде, аннары ОВЗ һәм инвалидлык белән авыручыларга мөмкин булган ярдәм чаралары турында ачык диалог форматында дискуссия уздырылды.

Декабрь аеның беренче атналыгында **психологик атналык** уздырылды. Балаларга төрле дәресләр оештырылды. Бу дәресләр укучыларга үз-үзләренә ышанычны арттыра. Мөстәкыйль фикерләү сәләтен баета. Иптәшләре арасында дуслыкны ныгыта.

12 декабрьдә **Россия Федерациясе Конституциясе көне** билгеләп үтелә. Бу истәлекле көн уңаеннан укучылар онлайн чарада катнаштылар. Балалар “сорау-җавап”, “әкиятне таны”, анаграммалар бәйгеләрендә катнашып, үзләренең белемнәрен күрсәттеләр. Укучылар мәктәптән үк безнең дәүләтебезнең төп нигезләре белергә, сәяси, икътисади, социаль һәм рухи өлкәләрендә белемле булырга тиешләр. Киләчәк тормышларында бу аларга, һичшиксез, кирәк булачак.

***Ләйсән Закирова, VII сыйныф укучысы***

***(Башы беренче биттә)*** Әти-әниләр, балаларның виртуаль уеннарына, зинһар, игътибарлы булыгыз! Хәзерге вакытта баланың исәнлегенә, психик халәтенә зарар сала торган уеннар бик күп таралды. Технологик яктан зур үсеш алган тормышта виртуаль дөнья чынбарлыктан күпкә кызыграк. Алай гына да түгел, баланың баш мие смартфондагы яраткан уен, кушымтаны наркотик кебек кабул итә. Баш миендә дофамин, ягъни бәхет, канәгатьлек гармоны бүленеп чыга. Шуңа күрә баланың гел телефонда утырасы килә. Бу исә үз чиратында биологик дәрәҗәдә генә түгел, ә психологик дәрәҗәдә дә бәйлелек барлыкка китерә. Соңгысы балалар гына түгел, өлкәннәр өчен дә куркыныч. Балалар – безгә Аллаһ Тәгалә тарафыннан бирелгән амәнәт. һәр ата-ананың бурычы – баласына дөрес тәрбия бирү, аның сәламәтлеге турында кайгырту. Зинһар, балаларыбызны телефон колы итмик! Балалар белән ешрак сөйләшик, вакытны бергә үткәрик!

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***

## Бакчада гаилә бәйрәме /Безнең бәйрәмнәр/



Балалар бакчасында гаилә бәйрәме бик кызык булды. Балалар әти һәм әни турында матур җырлар җырладылар. Алар оста итеп биеделәр, матур итеп шигырьләр сөйләделәр. Мәдинә һәм Ислам скетч куйдылар. Әни ролен – Мәдинә, ә малай ролен Ислам уйнады. Улы әнисенә әйтте:“-Әни, мин әтигә булыштым, идән юдым, савыт-саба юдым, һәм бәрәңгене сабын белән юдым“. Әнисе аны бик каты мактый иде, ләкин ул соңыннан шаккатты, чөнки бәрәнгене сабын белән юмыйлар бит. Шуннан соң ул малаеның ялгышын төзәтте.

Бәйрәмдә балалар әтиләре һәм әниләре белән төрле күңелле уеннар уйнадылар. Бәйрәмнең ахырында әти-әниләр һәм балалар тәмләп ашадылар, чәй эчтеләр. Минем үземә дә бу бәйрәм бик ошады, чөнки анда сеңелем дә катнашты.

***Асия Нурматова, V сыйныф укучысы***

## Яңа ел тамашасы



Яңа ел бәйрәме балалар өчен ниндидер могҗизалы тамашалардан торырга тиеш кебек. Укучылар бу чарага башкача әзерләнә. Быел да бәйрәмгә әзерләнеп һәр укучы кулдан эшләнмәләр, рәсемнәр ясады. Югары сыйныф балалары плакатлар белән бәйрәм залын бизәде. Чыршы да бизәлгән, бәйрәмгә әзер идек инде. Башлангычларның чыгышларын сәләтләренә карап сайладык. Барлык укучылар да үз кочләреннән килгәнне өйрәнеп, якыннарын сөендерәселәре килә. Серле тартма ясап, якыннарына бүләкләр дә әзерләделәр. Шул тартмага үзләренең салып, бирәсе килгән бүләкләрен ияләренә тапшырдылар. Бүләкләр әле моның белән генә бетмәде. Район башлыгы тарафыннан да һәр бала Яңа ел күчтәнәче тапшырылды. Аннан елның иң актив, иң алдынгы, төрле конкурсларда һәм олимпиадаларда урыннар алган укучыларга директорыбыз грамоталар тапшырды.

Балаларның чыгышлары бер-бер артлы шигырь, җыр белән үрелеп барды. Гыйбрәтле, тәрбияви чыгышлары да бик отышлы чыкты укучыларның. Балалар бакчасыннан килгән нәни артистлар тагын да кызыклы булды. Аларның елмаюларыннан күпме көч тә алып калдык. Кечкенәрәк сыйныф укучыларының да чыгышлары, әлбәттә, һәркемнең күңеленә хуш килә. Самимилек, гадилек бөркелеп торган йөзләр белән ясалган чыгышлар кемне генә битараф калдырыр икән?

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***

## Серле бәйрәм киче



Безнең Яңа ел тамашасының югары сыйныфлар өчен уздырылганында катнашасыбыз килде. Сыйныф җитәкчебез безнең кичке бәйрәмдә катнаша алуыбызны җиткергәч, бик шатландык. Чөнки үзебезне зур үстек дип тә тоясыбыз килә. Бу кичке чара ничектер серлерәк дә тоела. Башка төрле уеннар, бүләкләрне дә башкача биреп була.

Кичке бәйрәмгә һәр сыйныф чыгышлар әзерләде. Тамаша Солтан сараенда башланып китте. Солтанның зур гаиләсе биюләр башкарды, җырлар җырлады. Аларның тамашасы эчендә безнең дә җыр, биюләребез кушылып барды.

Тәмле сыйлар белән тулы өстәлләр бәйрәмгә тагын да ямь өстәде. Без иртәдән үк ризыкларыбызны әзерләп куйдык. Матур итеп табыннар кордык. Өстәл әзерләүдә әниләребез дә катнашты. Бу эш бергә эшләгәч, кызык та, җиңел дә булды. Ашханәдә эшләүче апаларыбыз кайнар ризыклар әзерләргә булышты.

Бәйрәмнең икенче өлешендә серле бүләкләрне тапшыру башланды. Бүләк алган дусларым бар да шундый шат иде. Бүләкне бирү дә, алу да бик сөенечле вакыт бит. Аннан алдан лотерея билетлары алган идек. Аларның да бөтенесе отышлы булгач, бигрәк тә шатлык булды. Мин ике билетыма да кирәкле әйберләр оттым. Ахырдан биюләр булды. Фотоларга төштек. Бәйрәмебез шундый ошады, рәхәтләнеп ял иттек. Оештыручы апа, абыйларыбызга рәхмәтебезне җиткерәбез!

***Ләйсән Закирова, VII сыйныф укучысы***